**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге Яңа Иглай авылы торак пунктында гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

«24» ноябрь 2023 ел № 8

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Иглай авыл җирлеге Яңа Иглай авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

Яңа Иглай авыл җирлеге территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидларыннан тыш, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, СВОда катнашучылардан кала 2024 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- су белән тәэмин итү системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, лицензияләү, төзү һәм ремонтлау, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм эчәр су белән тәэмин итү максатыннан халыкка су бирүне тәэмин итә;

- Яңа Иглай торак пункты чикләрендә авыл эчендәге юлларны карап тору һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тору;

- Яңа Иглай авылы территориясен төзекләндерү һәм карап тоту өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу.

Халык җыенында рәислек итүче: И.Х. Хәнәфиев

Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы И.Х. Хәнәфиев